ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге составына керүче Ташкичү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 20 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Ташкичү авылы, Чишмә урамы, 28А адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Россия Армиясе сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүдән үзара салым кертүгә ризамы?:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ташкичү торак пунктының Чишмә урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (вак таш сатып алу һәм салу, ПГС, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

- торак пункт чикләрен дә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (Ташкичү торак пунктында юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Ташкичү торак пунктында урамнарны энергияне саклый торган лампалар сатып алу, урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- торак пунктта су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (җайланмалар һәм материаллар сатып алу, Транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына Ташкичү торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Н.С.Рәфыйков